| МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | Казан шәһәре | **БОЕРЫК** |
| 7.09.2018 | | №208-ОД |

Татарстан Республикасы
Сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының норматив
хокукый актларына һәм норматив
хокукый актлары проектларына
коррупциягә каршы экспертиза
үткәрү тәртибен раслау турында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карарын үтәү йөзеннән, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең кушымтада бирелә торган тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аппараты бүлекләре, секторлары җитәкчеләренә Тәртип таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.Ш.Хөсәеновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр А.Ә.Кәримов

Татарстан Республикасы
Сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының 2018 елның
7 сентябрендәге 208-ОД
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе

1. Әлеге Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары нигезендә эшләнде һәм, аларга хокукый экспертиза уздырганда һәм аларны куллануга мониторинг үткәргәндә, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының (алга таба – Министрлык) норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү процедурасын билгели.

2. Министрлыкның чыгарылган норматив хокукый актлары (алга таба – норматив хокукый актлар) һәм Министрлык аппаратының структур бүлекчәләре тарафыннан эшләнелә торган норматив хокукый актларның проектлары (алга таба – норматив хокукый актлар проектлары) коррупциягә каршы экспертизага тиешле.

3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты – норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба бетерү.

Министрлыкта норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертизаны оештыруның төп принциплары булып түбәндәгеләр тора:

1) норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең мәҗбүрилеге;

2) башка норматив хокукый актлар белән үзара бәйләнештә норматив хокукый актны (норматив хокукый акт проектын) бәяләү;

3) норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләренең нигезлелеге, объективлыгы һәм тикшереп булучанлыгы;

4) норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) коррупциягә каршы экспертиза үткәрүче затларның компетентлыгы;

5) норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) коррупциягә каршы экспертиза уздырганда Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затларының граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлеге.

4. Коррупциягә каршы экспертиза «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары белән расланган Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе, әлеге Тәртип, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән Методика (алга таба – методика) нигезендә Министрлыкның юридик бүлеге җитәкчесе яисә, Министрлыкның юридик бүлеге җитәкчесе булмый торган чорда (командировка, отпуск, авыру һ.б.), аның вазыйфаларын башкара торган зат тарафыннан үткәрелә.

5. Норматив хокукый акт проектын әзерләү өчен җаваплы Министрлык аппаратының структур бүлекчәсе тарафыннан эшләнгән норматив хокукый акт проекты электрон документ әйләнеше системасы буенча хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен Министрлыкның юридик бүлегенә җибәрелә.

6. Норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза аларның хокукый экспертизасы Министрлыкның юридик бүлегенә электрон документлар әйләнеше системасы буенча кергән көннән алып биш эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә үткәрелгән очракта гамәлгә ашырыла.

7. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча, норматив хокукый акт проекты Министрлыкның юридик бүлегенә электрон документ әйләнеше системасы буенча алынган көннән башлап алты эш көне узганчы Министрлыкның юридик бүлеге җитәкчесе яисә, ул вакытлыча булмый торган чорда (командировка, отпуск, авыру һ.б.), аның вазыйфаларын башкара торган зат тарафыннан имзаланган, әлеге Тәртипкә кушымта булган форма нигезендә бәяләмә төзелә.

Бәяләмәдә түбәндәге мәгълүматлар чагылдырыла:

- экспертизага тәкъдим ителгән норматив хокукый акт проектының реквизитлары;

- норматив хокукый акт проектында коррупциячел факторлар булуы яки булмавы;

- коррупциячел факторлар булган норматив хокукый акт проектының

конкрет нигезләмәләре (коррупциячел факторларны ачыклаганда);

- коррупциячеллекне (коррупциячел факторлар ачыкланган очракта) бетерү өчен, норматив хокукый акт проекты нигезләмәләренең тәгъбирләнешләрен үзгәртү яисә аерым нигезләмәләрне төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр.

8. Министрлыкның юридик бүлегеннән коррупциягә кршы экспертиза уздырылганда ачыкланган коррупциячел факторлар күрсәтелгән бәяләмә алынган очракта, норматив хокукый акт проектын әзерләү өчен җаваплы булган Министрлык аппаратының структур бүлекчәсе норматив хокукый акт проектын эшләп бетергәндә аларны исәпкә ала һәм эшләп бетерелгән норматив хокукый акт проектын, карау өчен, Министрлыкның юридик бүлегенә кабат җибәрә.

9. Министрлыкның норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен, әлеге документларны эшләүче норматив хокукый акт проектын җыелма бүлеккә юллый, ул аларны Министрлыкның юридик бүлегенә карау өчен җибәрелгән көнгә туры килә торган эш көне эчендә аларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кысаларында оештырылган, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм иҗтимагый фикер алышу максатларында норматив хокукый актларның проектларын урнаштыру өчен, норматив хокукый актларның проектларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм иҗтимагый фикер алышу максатларында урнаштыру өчен бердәм төбәк интернет-порталы буларак билгеләнгән мәгълүмат ресурсында (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштыра. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен норматив хокукый актлар проектларын урнаштырганда, аларны эшләүче бәйсез экспертиза үткәрү, проект буенча тәкъдимнәр кертү сроклары, шулай ук бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталары, тапшырылган эксперт бәяләмәләрен һәм тәкъдимнәрен җыю, гомумиләштерү һәм исәпкә алу өчен җаваплы белгечләр исемлеге, аларның телефон номерларын, факсларын һәм электрон почта адресларын күрсәтеп, норматив хокукый актлар проектлары буенча эксперт бәяләмәләре һәм тәкъдимнәр җибәрү өчен мәгълүмат күрсәтә.

Шул ук вакытта Министрлыкның норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру чоры административ регламент проекты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба – Министрлык сайты) урнаштырылган көннән башлап биш эш көненнән дә азрак булмаска тиеш, Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү административ регламентларыннан тыш, ул административ регламент проекты Министрлык сайтында урнаштырылган көннән башлап 15 эш көненнән дә кимрәк була алмый.

Дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматлары яки конфиденциаль

рәвештәге мәгълүматлары булган норматив хокукый актларга, норматив хокукый актларның проектларына карата коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрелми.

Алар буенча иҗтимагый фикер алышу максатларында, Министрлыкның норматив хокукый актлары проектларын урнаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны һәм аларны әзерләгәндә иҗтимагый фикерне исәпкә алуны тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Татарстан Республикасы Президенты указын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны һәм аларны әзерләгәндә иҗтимагый фикерне исәпкә алуны тәэмин итү турында нигезләмдә билгеләнгән тәртиптә һәм очракларда гамәлгә ашырыла.

10. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә норматив хокукый акт проектын эшләүче тарафыннан аны алган көннән 15 көн эчендә мәҗбүри каралырга тиеш. Бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затка, бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш, нигезле җавап җибәрелә.

Норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциячел факторлар норматив хокукый акт проектын әзерләү өчен җаваплы булган Министрлык аппаратының структур бүлекчәсе тарафыннан норматив хокукый акт проектын эшләп бетерү стадиясендә юкка чыгарыла.

Норматив хокукый акт проектына аның коррупциягә каршы экспертизасын үткәргәннән соң үзгәрешләр кертелгән очракта, норматив хокукый акт проекты кабат коррупциягә каршы экспертиза узарга тиеш.

11. Министрлыкның норматив хокукый актларына коррупциягә каршы экспертиза аларны куллану мониторингы (алга таба – мониториг) вакытында үткәрелә.

Мониторинг Министрлыкның юридик бүлеге һәм Министрлык аппаратының норматив хокукый актларны эшләгән структур бүлекчәләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

12. Норматив хокукый актка мониторинг уздырылган көннән башлап өч эш көне эчендә Министрлыкның структур бүлекчәләре,, әгәр алар тарафыннан үзләре эшләгән норматив хокукый актка мониторинг барышында хокук кулланучы өчен гомуми кагыйдәләрдән искәрмәләрне нигезсез куллануны күздә тоту яки мондый мөмкинлекнең киң чикләре, гражданнарга һәм оешмаларга карата билгеле булмаган, авыр үтәлә торган һәм (яки) чикләүләр беркетә торган таләпләрнең нигезсез рәвештә билгеләнүен таныклый торган шартлар ачыкланса, норматив хокукый акт проектын нигезле дәлилләп, Министрлыкның юридик бүлегенә коррупциягә

каршы экспертизага җибәрәләр.

Норматив хокукый актка коррупциягә каршы экспертиза ул Министрлыкның юридик бүлегенә электрон документ әйләнеше системасы буенча алынган көннән башлап җиде эш көненнән артмаган чорда үткәрелә, аның нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган шул ук тәртиптә бәяләмә төзелә.

13. Министрлыкның юридик бүлеге бәяләмәсе нигезендә Министрлык аппаратының норматив хокукый актка мониторингны гамәлгә ашыручы структур бүлекчәсе, Министрлыкның норматив хокукый актында ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү максатларында, бәяләмәне алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көнлек чорда әлеге Тәртип нигезендә тиешле норматив хокукый актка үзгәрешләр яки өстәмәләр кертү турында норматив хокукый акт проектын әзерли һәм Министрлыкның юридик бүлегенә кертә.

14. Норматив хокукый акт проектын әзерләү яисә норматив хокукый акт мониторингын гамәлгә ашыру өчен җаваплы булган Министрлык аппаратының структур бүлекчәсе, Министрлыкның норматив хокукый актларында һәм Министрлык тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актларның проектларында коррупциячел факторлар булуы турында таныклый торган бәйсез (коррупциягә каршы бәйсез) экспертиза нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, законнарда билгеләнгән тәртиптә әлеге норматив хокукый актларны, норматив хокукый актларның проектларын, коррупциягә каршы бәйсез экспретиза бәяләмәсен һәм үзенең риза булмавын нигезләп, аңлатма язуын теркәп, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупциягә каршы экспертизага җибәрүне тәэмин итә.

15. Хокук куллану мониторингы кысаларында гамәлгә ашырылган норматив хокукый актка коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелә торган тиешле мәгълүмат составына кертелә.

Татарстан Республикасы
Сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының норматив
хокукый актларына һәм
норматив хокукый актлары
проектларына коррупциягә
каршы экспертиза уздыру
тәртибенә кушымта

Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча бәяләмә

______________________________________________________________

(норматив хокукый актның/норматив хокукый акт проектының исеме күрсәтелә)

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының 1 өлешендәге 3 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру кагыйдәләре һәм Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы нигезендә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының юридик бүлеге тарафыннан, анда коррупциячел факторларны ачыклау һәм аларны алга таба бетерү максатларында, экспертиза уздырылды

______________________________________________________________

(норматив хокукый актның/норматив хокукый акт проектының исеме күрсәтелә)

1 вариант:

Кайда ______________________________________________________

(норматив хокукый актның/норматив хокукый акт проектының исеме күрсәтелә)

коррупциячел факторлар ачыкланмады.

2 вариант:

Кайда ______________________________________________________

(норматив хокукый актның/норматив хокукый акт проектының исеме күрсәтелә)

түбәндәге коррупциячел факторлар ачыкланды: ___________________________

______________________________________________________________

(коррупциячел факторлар булган норматив хокукый акт проектының конкрет нигезләмәләре күрсәтелә)

Ачыкланган коррупция факторларын бетерү максатларында тәкъдим ителә:

______________________________________________________________

(коррупциячел факторларны бетерү ысулы күрсәтелә: норматив хокукый акт проекты нигезләмәләренең

тәгъбирләнешләрен үзгәртү (аны башка редакциядә бәян итү, норматив хокукый акт проекты текстына башка үзгәрешләр кертү, аерым нигезләмәләрне төшереп калдыру яисә башка ысул)

_______________________________________________________________________________________

«__» ___________ 20__ ел.

____________________________ _______________ _________________________________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза)